**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**23.10.2019** **№1796**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында”, 2018 елның, 29 декабрендәге, 1270 карары белән эш йөртеп, педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә дәүләт ярдәме һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы педагогик кадрларын урында калдыру максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне 1 111 сум күләмендә итеп, укыту йөкләнеше, эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә, әмма бер педагогик хезмәткәргә – яшь белгечкә 1 111 сумнан да артмаган күләмдә итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне түләү өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү Тәртибен расларга (кушымта).

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – мәгариф бүлеге начальнигы Әхмәтҗанов Н.К.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

«Расланган»
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
23.10. 2019 № 1796

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне түләү өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне түләү өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү механизмын ачыклый (алга таба – башка бюджетара трансфертлар).

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга, билгеле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә биреләләр.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүчеләр булып, Татарстан Республлтикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы тора (алга таба – Тармак министрлыгы).

4. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан территориясендә муниципаль белем бирү учреждениеләре урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына, ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләнгән педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә бирелә.

5. Муниципаль берәмлеккә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме, түбәндәге формула аша билгеләнә:

$$S_i = D \times k_i \times 12 \times e,$$

монда:

$S_i$ – *i* муниципаль районга хезмәткә түләү буенча түләүләргә өстәмәләрне исәпкә алып, башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

D – *i* муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмада эшләүче педагогик хезмәткәргә – яшь белгечкә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү, 1 111 сум күләмендә;

12 – елдагы айлар саны;

$k_i$ – *i* муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмаларда эшләүче педагогик хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең планлы саны;

e – законнар нигезендә бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәре күләме.

6. Билгеле финанс елына муниципаль берәмлекләргә башка бюджетара трансфертлар күләме бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

7. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) Тармак министрлыгына агымдагы елның 1 февраленә кадәр түбәндәге документларны тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар хисабына, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган, Биектау муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү бирү тәртибе;

Тармак министрлыгы белән расланган формада башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза;

Биектау муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында гаризаны имзалаган затның вәкаләтләрен раслаучы документ;

Тармак министрлыгы боерыклары белән расланган формада, Биектау муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләр реестры;

Билгеле муниципаль берәмлекнең бюджетында Татарстан Респбликасы Биектау муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүләр түләү өчен чаралар булуын раслаучы документ.

8. Тармак министрлыгы әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны, алар кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләп, 10 көнлек срокта карый.

Башкарма комитет тарафыннан әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны тулы булмаган күләмдә яки әлеге Тәртипнең 7 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, Тармак министрлыгы документларны кире кайтара һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, Башкарма комитетка документлар пакетын кире кайтару турында биш көн эчендә хәбәр итә.

Башкарма комитет документлар пакетын кире кайтару турында хәбәрнамә алган көннән башлап өч көн эчендә, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшырырга хокуклы.

9. Тармак министрлыгы әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны кабат мәртәбә, алар кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләп, 10 көнлек срокта карый.

10. Башка бюджетара трансфертлар Тармак министрлыгы һәм Башкарма комитет арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү нигезендә биреләләр (алга таба – Килешү).

Килешү Тармак министрлыгы раслаган формада бирелгән документларга куелган билгеле таләпләрне Тармак министрлыгы тарафыннан караганнан соң, эш көннәрендә исәпләп, 10 көн эчендә төзелә.

11. Тармак министрлыгы квартал саен башка бюджетара трансфертларны, Федераль казначылык территориаль органнарында ачылган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы шәхси счетларына күчерә.

12. Башкарма комитет Тармак министрлыгына әлеге Тәртипкә кушымтадагы форма нигезендә, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 нче числосына кадәр педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштырыла торган өстәмә

түләүне түләүгә башка бюджетара трансфертларны файдалану турында хисап тапшыралар.

13. Башкарма комитет һәм аның вазыйфаи затлары законнар нигезендә, хисап мәгълүматлары һәм башка бюджетара трансфертларны максатчан кулланмаган өчен җаваплылык йөртәләр.

14. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны контрольдә тотуның закон нигезендә Тармак министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тормышка ашыра.

15. Башкарма комитет тарафыннан бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан кулланмау, закон нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акчалар һичшиксез кире кайтарылырга тиеш.

16. Агымдагы финанс елының 1 нче гыйнварына кулланмаган башка бюджетара трансфертлар  Татарстан Республикасы бюджет керемен ә, агымдагы финанс елының  беренче 15 көне дәвамында кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларда ихтыяҗ булуы турында Тармак министрлыгы карары нигезендә, хисап финанс елында кулланылмаган, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар  күләменнән артмаган күләмдә, моңа кадәр бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемен ә, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килгән муниипаль берәмлек чыгымнарын финанс тәэмин итү өчен, агымдагы финанс елында кире кайтарылырга мөмкин.

Әгәр дә  башка бюджетара трансфертларның кулланылмаган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемен ә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән чаралар Татарстан Республикасы бюджеты керемен ә, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы ачыклаган тәртиптә, Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы куйган гомуми таләпләрне күздә тотып, кире кайтарылырга тиеш.

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне түләү өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бирү Тәртибенә

Форма

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне түләүгә башка бюджетара трансфертларны куллану турында
хисап

| Чыгымнар функциональ статьясының коды | Педагогик хезмәткәрләр – яшь белгечләр саны, кеше | Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне түләүгә финансланган, сум | | | Өстәмә түләүне түләү өчен чыгарылган чыгымнар (хисап чорына күчерелгән акчалар күрсәтелә, ел башыннан үсә бару тәртибендә), сум | | | Кулланылмаган чараларның калган өлеше, сум | | | Ай саен стимуллаштыручы устәмә түләүнең уртача күләме (иминият кертемнәрен исәпкә алып) 6 графа/ 2 графа / хисап чорында айлар саны, ум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән | | барлыгы | шул исәптән | | |
| | | | ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне тормышка ашыру | дәүләт бюджеттан тыш фондларына иминият кертемнәрен түләү | | ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне тормышка ашыру | дәүләт бюджеттан тыш фондларына иминият кертемнәрен түләү | | ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләүне тормышка ашыру | дәүләт бюджеттан тыш фондларына иминият кертемнәрен түләү | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 0701 мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | | | | | | | | | | | |
| 0702 гомуми белем бирү учреждениеләре | | | | | | | | | | | |
| 0703 балаларга өстәмә белем бирү оешмалары | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | | | |

Башкарама комитет җитәкчесе _____________________

Мәгариф бүлегенең баш бухгалтеры ____________________

Башкаручы _____________________ телефон № ____________